Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советы

Богородский авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

18 декабрь, 2024 ел № 15

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегендә Гавами фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, 2017 елның 21 августындагы 80 номерлы (2017 елның 14 декабрендәге 94 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 108 номерлы, 2019 елның 2 октябрендәге 156 номерлы, 2022 елның 12 декабрендәге 62 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 70 номерлы, үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегендә авыл җирлегендә яшәүчеләрнең проектны гавами тыңлаулар уздыру юлы белән фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитетына гавами тыңлауларны оештыручыга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

3. Гавами тыңлаулар үткәрү 2025 елның 18 гыйнварыннан да соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) , Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары В.М. Барышев